# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 3 Бәйрәкә авылы 16 март 2020 ел.

*Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында*

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 15 маддәсендәге 4 өлеше, «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Бәйрәкә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Ютазы муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтләренең җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрен хәл итүне тапшыру мәсьәләсен тәкъдим итәргә:

- җирлекләрнең мөлкәтен исәпкә алуны тәэмин итү һәм оештыру, аның реестрын алып бару, шул исәптән торак фонды объектлары, җирлекләрнең муниципаль милек реестрыннан өземтәләр бирүне;

- гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә һәм шартларда, шул исәптән мөлкәтне хуҗалык алып бару һәм муниципаль бюджет учреждениеләренә оператив идарә итү хокукында беркетү, шулай ук алар арасында мөлкәтне яңадан бүлү буенча;

- җирлек милкендә булган муниципаль милек реестрын, шулай ук Ютазы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген урнаштыру вәкаләтләре.

2. Ютазы муниципаль районы Советы әлеге карарның беренче өлешендә күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитеты:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән әлеге карарның беренче өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләрне кушымта нигезендә типлаштырылган форма

нигезендә тапшыру турында килешү төзергә, төзелә торган килешүләрнең гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирлекнең бюджет-финанс комиссиясенә йөкләргә.

Бәйрәкә авыл җирлеге
башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.О.Ахметшина